Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Бута авыл Советы

# КАРАР

14 декабрь 2023ел № 88

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бута авыл Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бута авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында» 2021 елның 29октябрендәге 29 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 2 ноябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә

Бута авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1.Әлмәт муниципаль районы Бута авыл Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бута авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында» 2021 елның 29октябрендәге 29 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бута авыл Советының2023 елның 20февралендәге66 номерлы, 2023 елның 1 августындагы 79 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Муниципаль хезмәткәрләргә классլы чиннар бирү һәм муниципаль хезмәткәрләрне муниципаль хезмәтнең башка вазыйфаларына күчергәндә һәм муниципаль хезмәттән азат ителгәндә аларны саклап калу тәртибе» 4 бүлегендә карарга кушымталар:

- 4.6 пунктындагы 4.6.1 пунктчасында икенче җөмләне төшереп калдырырга;
- 4.10 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;
- 4.13 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәткәргә классլы чин бирү турындагы карар, 4 бүлекнең 4.7 пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затына барлык кирәкле документлар белән классլы чин бирү турында тапшыру кертелгән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.».

2. Әлеге карарны Бута ав., Сельская ур., 28А йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Бута
авыл җирлеге башлыгы Д.Е. Абрамов

Scanned with AnyScanner